**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

**утызынчы утырыш**

**26 июль 2024 ел** **№130** **Теләче ав.**

**Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 16.06.2009 № 7 «Теләче авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 16.06.2009 №7 «Теләче авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (12.03.2021 N 15, 10.03.2022 N 51, 16.12.2022 № 83 карарлар редакциясендә),түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган, Теләче авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәгә:

а) 2.5 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;

б) 2.6 пунктта «Белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетада булган белешмәләрдән тыш)» сүзләре белән тулыландырырга

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Хаҗипов